**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әсәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әсәй авылы №59-28 «03» июнь 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында " 2016 елның 19 апрелендәге 30 нчы карары үз көчен югалткан дип санау турында

2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы тору турында» гы Федераль законы, «Муниципаль вазифага яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына дәгъвалаучы гражданнарның, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турында»гы Татарстан Республикасы 2017 елның 19 июлендәге 56нчы Законы нигезендә

**Әсәй авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында " 2016 елның 19 апрелендәге 30 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.
2. Әлеге карарны Әсәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәис З.Ә. Идрисов.